РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Краснокадкинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423558, Нижнекамский район,
с. Верхние Челны, ул. Молодежная, 13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл җирлеге
Советы

423558, Түбән Кама районы,
Югары Чаллы авылы, Яшьлэр урамы, 13

тел./факс (8555) 44-50-21, электронный адрес: Krasnokadkin.sp@tatar.ru,
сайт: www.krasnokadkinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.07.2021 ел № 14

Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының «Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының «Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 30 номерлы карары белән (алга таба – карар) расланган Кызыл Чапчак авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Тәртипнең 3 бүлегендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге башкарма комитеты тора.».

1.2 Тәртипнең 3 бүлегендәге 6 пункты 6.3 пунктчасының 2 абзацын һәм 4 бүлегендәге 3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В. Илдарханов